ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**_2019 елның 23 декабре_** **Чистай шәһәре** **704**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 27 февралендәге 100 номерлы карары
белән расланган «Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында «Мәктәпкәчә
белем бирү (балалар бакчалары)төп гомуми
белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
мәгариф оешмаларына балаларны
исәпкә кую һәм кабул итү»
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
Административ регламентына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 елның 2 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары)төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау турында»гы боерыгы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1.2 пунктының унбишенче абзацы. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 февралендәге 100 номерлы карары (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 октябрендәге 557 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль

районында «Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары)төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бер гаиләдә һәм гомуми яшәү урыны бер үк булган балалар төп гомуми белем бирү программалары буенча энеләре һәм (яки) сеңелләре белем ала торган дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия».

2. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (О.В. Купцовага) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында https://pravo.tatarstan.ru//урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы О.В. Купцовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов